ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру барышы турында

«Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Д.Ф. Шәйдуллин мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру барышы турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. «Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында эшләрне, аларны инженерлык коммуникацияләрен алмаштыру программалары белән синхронлаштыруны тәэмин итеп, үз вакытында башкару һәм аларның сыйфатын тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан ишегалды территорияләрен төзекләндерү барышына халыкны җәлеп итүне мониторинглауны дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына ишегалды территорияләрен төзекләндерү барышына халыкны җәлеп итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасының ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларына «Безнең ишегалды» республика программасы кысаларында төзекләндерелгән ишегалды территорияләрендә инженерлык коммуникацияләрен алмаштыру эшләрен башкарганда ишегалды территорияләрен төзекләндерүнең расланган схемалары нигезендә юл өслекләрен торгызуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына Татарстан Республикасында республика башкарма хакимиятенең тармак органнары һәм җирле үзидарә органнары

белән берлектә ишегалды территорияләрен төзекләндерү өлкәсендә норматив җайга салуны мониторинглауны дәвам итәргә.

6. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Безнең ишегалды» республика программасы кысаларында билгеләнгән кече архитектура җиһазларына сакчыл мөнәсәбәт зарурлыгы турында халыкка мәгълүмат җиткерүдә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Дәүләт Советы Рәисе<br>
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре<br>
2026 елның 4 июне<br>
№ 175-VII ДСП